ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

15 февраль 2019 ел №169

Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәнең үз көчен югалтуын тану хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советы карар итә:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы авыл җирлеге «14» март, 2014 ел 7 номерлы карары белән расланган Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәнең үз көчен югалткан дип санарга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Апас шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары Н.Т. Исмагиловка йөкләргә.

“Шәһәр тибындагы Апас поселогы”
муниципаль берәмлек Башлыгы,
Апас шәһәр җирлеге Советы рәисе Р.Н. Заһидуллин